Шәйхи Маннур

Кояш, чык, чык!

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
М 23

Маннур Шәйхи

М 23 Кояш, чык, чык! Шигырьләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. — 24 б.

Танылган шагыйрь Шәйхи Маннурның балалар өчен язган иң яхшы шигырьләрен туплаган бу китап аның тууына 100 ел тулу уңаеннан чыгарыла.

ISBN 5-298-01447-х

© Татарстан китап нәшрияты, 2005

Шәйхи Маннур

Кояш, чык, чык!

Шигырьләр

Рәссамы ***Илдус Әҗемов***



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2005

Яхшы бел

Татарча да яхшы бел,
Урысча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.

Татарчасы — туган тел,
Безгә газиз булган тел.
Атаң-анаң, әби-бабаң
Сине сөя торган тел.

Бу телдә рух байлыгың
Һәм йөрәк кайнарлыгың.
Җырлаган бу телдә безгә
Сөекле Тукай моңын.

Тел кешене дус итә,
Бер-беренә беркетә.
Бел, балам, син рус телен
Һәм онытма үз телең!

Кояш, чык, чык!

Яз көннәре килгәндә,
Тау өстендә, чирәмдә
Утырабыз җыйнаулап,
Бишәү түгел, унаулап.

Кояш кача болытка,
Без калабыз суыкта.
Ә безгә җылы кирәк,
Су керергә тизрәк.

Әй сорыйбыз кояштан,
Барыбыз бертавыштан:
— Кояш, чык, чык!
Синең җылың бик тансык,
Чыксаң, без сөенербез,
Майлы ботка бирербез,
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.
Тәти кашык саф алтын,
Кирәкми безгә салкын!

Күгәрченнәр гөрли

Иртүк безнең түбәләрдә
Күгәрченнәр гөрләгәндә,
Уянам мин йокыдан.
Урын җыям,
Өеп куям,
Бит юарга тотынам.

Ә күгәрченнәр һаман
Мине сөйлиләр сыман:
— Кү-гү-гү,
— Кү-гү-гү,
— Иртә торган бу,
— Кү-гү-гү...

Чыгам ишек алдына мин,
Яулык бәйлим алдыма мин,
Утырам да чәч тарыйм.
Тарасам да,
Юл ачсам да,
Күгәрченнәргә карыйм.

Ә күгәрченнәр гөрли,
Әйтерсең мине сөйли:
— Кү-гү-гү,
— Кү-гү-гү,
— Юк, ялкау кыз түгел бу,
— Кү-гү-гү...

Әни киткән фермасына,
Әби чыга бакчасына,
Миңа да ул эш куша.
Ә мин елыйм,
Ямансулыйм,
Эш кушсалар, эч поша.

Ә күгәрченнәр гөрли,
Янәсе, мине әрли:
— Күгү-гү,
— Күгү-гү,
— Юк, әйбәт кыз түгел бу!
— Күгү-гү.

Булмасын

Минем әти капитан,
Германиядән кайткан.
Утлар, суларны кичкән,
Берлинга барып җиткән.

Фашистларны җиңгән ул,
Сугышны бетергән ул,
Илдә бөтен кешегә
Тынычлык китергән ул.

Минем дәү кызым, дигән,
Тыныч укысын, дигән,
Аның дус кызлары да
Шундый ук булсын, дигән.

Ләйлә белән Камилнең,
Сөмбел белән Наилнең
Әтисе дә сугышкан,
Безнең өчен тырышкан.

Алар бергә йөргәннәр,
Бергә-бергә җиңгәннәр.

Инде минем әтием,
Кабат аерылмабыз, ди.
Үзебез исән чакта,
Сугыш булдырмабыз! ди.

Әллә кайда, еракта,
Комсызлар торган якта —
Тагын телиләр, имеш,
Булсын дип сугыш, үлеш.

Булмасын ул, булмасын,
Кирәкми безгә сугыш!
Булмасын бер куркыныч,
Булсын бөтен ил тыныч!

Күзлек кайда?

— Безнең әбигә ни булган?
— Аның күзлеге югалган!

Әби, мескен, капшый барсын —
Мендәр артын, юрган астын.

Матрас асларына җитә —
Башы белән кереп китә.

Карый чиләк, чүлмәк эчен,
Итек, башмак, чүәк эчен.

Өйдәге бар әйберләрнең
Астын өскә әйләндерде.

Хәл җыярга утырды ул,
Сукранды ул, пошынды ул.

Һәм күзлеген өр-яңадан
Эзли башлады ул аннан.

Тагын капшый мендәр астын,
Тагын карый кисмәк артын.

Кухняда ул, шәм яктыртып,
Мичкә керде, шәмен тотып.

Эзләп чыкты чоланнан да —
Бушка гына ләкин бар да!

Юкка чыкты күзлек шулай —
Ахры, урлаганнар бугай!

Утырды ул арып шунда.
Көзге тора каршысында.

Күрде әби: ул күзлеген
Эзләгән һич юкка бүген.

Күзлек аның маңгаенда
Булган икән шул чагында!

Шулай серле пыяла
Күзлеген тапты аңа!

Бәбкәләр

Әйләнә-тирәләрдә,
Ямь-яшел чирәмнәрдә
 Япь-яшь бәбкәләр йөри;
Чирәм тартып өзгәндә,
Койрыгын җиргә тери.
Алар бик сөйкемлеләр,
Уенчык шикеллеләр.

Йоннары йоп-йомшак,
Тәпиләре гәрәбә,
Борыннары балавыз.
Кызыгам бер сөяргә!
Ата каз гына явыз:
Киләдә чукып ала,
Бот итен йолкып ала!..

Яратмыйм шул явызны —
Аяу белмәс авызны,
Бәбкәләрне яратам.
— Лил-лил-лил! — дип чакырам да
Ипи турап ашатам.
Куаналар:
— Пи-пи-пи!
— Тәмле булды бу ипи!..

Әйләнә-тирәләрдә,
Ямь-яшел чирәмнәрдә
Тагын алар йөргәли,
Үлән тешләп өзгәли,
Өзгәч, җиргә чүгәли.
Алар бик сөйкемлеләр,
Уенчык шикеллеләр!

Апам белән

Минем апам Лилия
Сатин күлмәген кия,
Сары алъяпкыч яба,
Чәчләрен үреп сала.
Китап, каләм ала да,
Сумкасына сала да,
Мәктәпкә китеп бара,
Ә мин озатып калам.

Аннары минем әни,
Әнием белән әти
Мине бакчага илтә,
Үзләре эшкә китә.

Мин тагын карап калам
Рәшәткәле бакчадан.
Аннары уйныйм, көләм
Бакча дусларым белән.

Ә киләсе елга мин,
Булмам инде монда, дим,
Аерылырмын сездән:
Мәктәпкә барам көздән.

Лилия апам белән,
Киенеп бертөрледән,
Китәрбез бер мәктәпкә,
Укырбыз «бик әйбәткә».

Хуш килдегез!

Исәнмесез, минем шаян дуслар!
Хуш килдегез, рәхим итегез!
Кулга тотып белем ачкычларын,
Йә, әйдәгез, түрдән үтегез.

Бу якты йорт сезнең бәхет өчен,
Бу китаплар сезгә нур чәчсен.
Эчләрендә булган әйбәт сүзләр
Иптәш булып сезгә эндәшсен.

Кояшның да бүген йомшак нуры
Сезне бире сөеп китерде;
Алыгыз сез гыйлем хәзинәсен
Һәм үсегез гөлләр шикелле!

Әлифба

— Нәрсә булган?
— Нәрсә булган?
— Мич кырыннан
Минем әлифбам егылган!

Аягын нык каймыктырган
Баш хәреф **М**, мескенкәй.
Г үз генә ботын борган,
Җ таралган бөтенләй.

Ю югалткан үзенең
Арадагы күперен!
Төшеп идәнгә кырын,
У сындырган койрыгын!

Ф, бичара, әй шешенгән —
Укый алырлык түгел!
Р ның асты-өскә килгән —
Йомшак билге төсле гел!

С бөгелгән егылып төшкәч,
Булган ул **О** шикелле.
А хәрефе, аңга килгәч,
Танымады һичкемне!



Мәктәп
ӘЛИФБА

Киңәш

Күзең белән кара син,
Күңлең белән уйла син,
Уен уйлап, язуыңны
Ялгыш язып куйма син.

Кат-кат уйла хисапны,
Дөрес чыгар шул чакны.
Уйла җитез, уйла тиз,
Биш кат үлчә, бер кат кис.

Дәфтәрең чиста булсын,
Китабың көлеп торсын.
Ачып җибәргәндә син,
Үзлегеннән укылсын.

Әйтеп кара

Мич башында
Биш мәче,
Биш мәченең
Биш башы.
Биш мәченең
Биш башына
Ишмә мич башы
Ташын.

•

Әвеш-тәвеш килә кәвеш,
Ары-бире барыбер.
Ары-бире йөри бүре,
Бүре өере тагы бер.

•

Карга кара, кара карга,
Кар-рык, кар-рык карылдама;
Кардан калка кара карга,
Кара каурыйлары карга
Тарала да аунап кала.
Мин әйтәлам, кем әйтәла?
Рамил, йә, син әйтеп кара.

Яратам

Яратам мин өемне,
Әти белән әнине,
Абый белән энемне,
Бишектәге сеңлемне.

Яратам мәктәбемне,
Укытучы апамны,
Дусымны, иптәшемне,
Уйнап йөргән бакчамны.

Алай итмә

Бик ярата шул Мәрфуга
Китапларны күп укырга.
Ятса да ул, торса да ул,
Суза тизрәк китапка кул.

Оныта урнын җыярга,
Бит юарга, чәч тарарга,
Чыкмый урамга уйнарга,
Китап булсын гел аңарга!

Ашарга дип утырса да,
Өстәлгә ул китап сала.
Бер укый да бер аш каба,
Белмим, нинди тәмен таба?

Ә минемчә: бутала ул,
Берни аңламый кала ул!

Алай итмә син, үскәнем,
Ашаганда бел аш тәмен,
Укыганда — китап тәмен,
Барысын да бергә бутап,
Җибәрмә син эшнең ямен!

Тырыш кыз

Зәйнәп хәзер бик зур инде,
Сигез яшьне тутырды.
Беренчене бетерә ул,
Бик ярата укуны.

Сабакларын хәзерли ул,
Бик әйбәтләп, тырышып.
Булмый аның дәфтәрендә
Бер кара тап, бер бозык.

Укуларын бетерә дә,
Әнисенә булыша,
Йә бәрәңге әрчеп бирә,
Йә савытлар юыша.

Зәйнәп идән дә себерә,
Чүпләрен түгеп куя.
Әтисенең китапларын
Матурлап өеп куя.

Сөртә өстәл тузаннарын,
Тәрәзә суын ала,
Үз урнын ул үзе җыя,
Төймәсен үзе тага.

Аннан Зәйнәп тышта уйный,
Йөри иркен һавада.
Рәхәтләнеп чана шуа,
Битләре алсулана.

Тагын да бар мактарлыгы:
Шаярып карга батмый,
Итекләрен пычыратмый,
Итәгенә боз катмый.

Шулай хәзер безнең Зәйнәп,
Бик үскән ул, бик уңган.
Укуны да бик ярата,
Эш тә килә кулыннан.

Әтисе дә, әнисе дә
Мактап бетералмыйлар.
«Бик тырыша безнең Зәйнәп,
Эшлеке кыз ул!» — диләр.

Шуңа күрә, шигырь язып,
Мин дә мактадым аны.
Ә сезнең эш ничек, кызлар?
Кемне мактыйм мин тагы?

Җәй җыры

Сау бул инде көзгә хәтле,
Китәбез, мәктәп, синнән.
Көтә безне җәй рәхәте,
Ул безнең өчен килгән.
Исәнме, әй,
Ямьле җәй!
Сәлам сиңа, яшел дус!
Бәллүдәй
Куйның͏ны җәй,
Чәчкә-гөлләреңне суз!

Чакыра җәй урманнарга,
Кошлар сайраган җиргә.
Тар, яшерен сукмакларда
Качып, уйнап йөрергә.
— Аһа-һа-һау!
Сез кайдау?
Килегез, дуслар, бире!
— Без мондау!
— Аһа-һа-һау!
— Кайдан табыйк без сине?

Чакыра җәй басуларга,
Походларга китәргә,
Әти, әни, абыйларга
Эштә ярдәм итәргә.
Исәнме, әй,
Ямьле җәй!
Көннәрең матур килсен.
Үстер, җәй,
Гәрәбәдәй
Бодайлар безнең өчен!

Су буе

Ай су буе, су буе
Ярында таллар куе,
Талларда кошлар туе,
Кайтып булмый көн буе!

Бик рәхәт безнең инеш:
Эсселәп килгән килеш,
Ташлыйсың да чишенеп,
Төшәсең бер сикереп!

Шау килә басма яны,
Без анда су кергәндә,
Онытып бар дөньяны,
Узып-узып йөзгәндә.

Сикерә Варис басмадан,
Чума ул суны ярып.
Мин аны эзләп табам,
Хәлләр бетә шаярып!

Чыгабыз су ярына,
Ауныйбыз комнарында.
Без инде шат
Мең-мең кат
Кояш кыздырганына!

Тагын кереп китәбез,
Чалкан ятып йөзәбез,
Әлләниләр эшлибез,
Һаман туктый белмибез.

Ә яр буенда Гыйльми
Чупырдап яткан була,
Ул әле йөзә белми,
Яңа сигез яшь тула.

Без аны өйрәтәбез:
Эчтәрәк йөздерәбез,
Кулын күнектерәбез
Һәм йөзеп күрсәтәбез.

Ә ул белми дә белми,
Без күрсәткәнчә йөзми;
Чапалана, кычкыра,
Тизрәк ярга ычкына.

Курыкма син бернидән,
Ишеп җибәр кул белән,
Аягың күтәр җирдән,
Кыю йөзәргә өйрән!

Шулай уйнап, шаярып,
Туңып бетәбез, арып;
Теш бәрелә тешләргә,
Киенгәндә өсләргә.

Ай су буе, су буе,
Кайтып булмый көн буе!

Яшь туристлар җыры

Юлга чыктык без бергә,
Туган илдә йөрергә.
Туган илнең төрле җирен,
Байлыкларын күрергә.

Мендек биек тауларга,
Йөрдек киң яланнарда.
Учак ягып, үлән түшәп,
Кундык без урманнарда.

Күрдек авыл йортларын,
Балкып янган утларын.
Алма бакчалары каплый
Авылларның як-ягын.

Күрдек без нефть җирләрен,
Дан алган эшчеләрен,
Алар безгә сөйләп бирде
Җир астының серләрен.

Без җырлашып үткәндә,
Юлдаш булды шаян җил.
Кай якларда йөрсәң дә,
Матур икән туган ил!

Күңел һаман сиңа тарта

Күңел һаман сиңа тарта,
Эндәшә һәр сукмагың.
Сагынам да сиңа кайтам,
И газиз туган ягым.

Кошларың күп,
Кояшың күп,
Шифалы яңгыр, җилең,
Беркайда да булмаган күк
Бар җирең матур синең.

Яланнарга чыгып йөрсәм,
Алсулана йөзләрем.
Чишмәләрең суын эчсәм,
Кайта яшьлек көчләрем.

Киң, бөек туган илемнең
Син — гүзәл бер почмагы.
Синдә үтте гомеремнең
Канатлы сабый чагы!

3 э-921



Печән җыйганда

Их, күңелле безнең болын,
Печән җыйганда.
Тугай саен сайлап урын,
Кибән куйганда.

Бөтен кеше шунда кайный,
Барысы эштә.
Матур булып җыр яңгырый
Ничәмә төштә!

Кызлар, актан киенешеп,
Ак тырма белән
Печән җыя, тезелешеп,
Болын түреннән.

Ә егетләр печән бирә
Кибән өстенә:
Бер чүмәлә бер элүдә
Җилтерәп менә!

Без — малайлар
Атта инде!
«Һайт!» та «һайт!» кына
Тарттырабыз печәннәрне
Кибән катына.

Хуш ис сибә кипкән печән,
Аңкый болыннар...
Кешнәп-ярсып, түзешмичә
Чаба колыннар.

Рәхәт тә соң печән өсте!
Бер бәйрәм төсле:
Кошлар сайрый,
Эшләр кайный,
Арттыра көчне!

Ике тәкә

Таулардагы сукмак текә,
Кайта шуннан кара тәкә.
Юлдагы бер тар басмада
Очырый ак тәкә аңа.

Ул ак тәкә әйткән моңа:
— Туганкай, эш җайсыз монда.
Үтеп булмый кара-каршы,
Син торасың минем юлда.

— Мә-ә-ә-ә! — дигән кара тәкә, —
Акыл бармы син тинтәктә?
Аякларым корганда да,
Мин торырмын бу басмада!

Берсе мөгез чайкап алган,
Берсе аяк терәп калган...
Ләкин мөгез чайкап кына
Үтеп булмый тар басмадан.

Сөзешкән бу ике тәкә,
Бер-беренә юл бирмәскә.
Икесе дә кире каткан,
Икесе дә суга баткан!

Җәйге кичтә

Кич булса, без тау башына
Җыелабыз уенга.
Гөрләшәбез, көлешәбез
Җәйге кич тынлыгында.

Йөгерәбез туп артыннан,
Куышабыз, качабыз.
Кыр казлары булып, таудан
Түбән таба очабыз.

Җилферди күлмәк җиңнәре,
Алар — безнең канатлар.
Тауга каршы менгәндә без —
Тыелмас ярсу атлар.

Ниләр генә уйнамыйбыз?
Хәлләр бетә — туймыйбыз.
Әй рәхәт соң җәйге кичтә,
Күңел ачып туймыйбыз!

Әкрен генә кояш байый,
Алтын сибеп йортларга.
— Сау бул, кояш!
Без дә инде
Таралабыз йокларга.

Иртәгесен тагын шулай
Без килербез уенга.
Җырлашырбыз, сайрашырбыз
Җәйге кич тынлыгында.

Кәҗә, кәбестә, бүре

Булган, ди, бер балыкчы,
Иделдә ау салучы.
Булган аның кәҗәсе,
Бүресе, кәбестәсе.

Ул аларны берзаман
Сатарга дип уйлаган,
Алып килеп Казанга,
Якшәмбе көн базарда.

Кирәк була боларга
Идел аша чыгарга.
Әмма ничек итәсе?
Балыкчының көймәсе
Кирәгенчә зур булмый,
Дүртесен дә сыйдырмый.

Шуның өчен аңарга,
Идел аша чыкканда,
Туры килә кәҗәне,
Бүрене, кәбестәне
Ташырга берәм-берәм
Шул җайсыз көймә белән.

Ләкин кайсысын алдан,
Яки кайсысын арттан
Алып китәргә ярдан?
Бүрене алып китсә,
Кәҗә белән кәбестә
Теге ярда кала да,

Балыкчы юк арада,
Кәҗә ашый кәбестәне.
Кәбестәне чыгарса,
Бүре һәм кәҗә калса,
Бүре буа кәҗәне.

Аптырый бит балыкчы,
Ник бер хәйлә тапсынчы? —
Кәҗә ашый кәбестәне,
Ә бүресе — кәҗәне!

Ягез, без уйлап карыйк:
Ничек итеп чыгарыйк
Идел аша боларны?
Һәм чыгарып буламы?

Сагынып кайттык

Көз килгәнен шуннан белдек:
Укыр вакытлар җитте,
Җәй көннәре, бер төш кебек,
Сизелми үтеп китте...

Сизелде ул сизелүен:
Лагерьларда булдык без,
Рәхәтләнеп ял итүнең
Тәмен, ямен тойдык без.

Күп уйнадык, күп җир күрдек,
Печәннәр күбәләдек,
Агач башларына мендек,
Комнарда тәгәрәдек,

Әнис җыйдык болыннарда,
Кузгалаклар, көпшәләр.
Йөргән чакта урманнарда,
Чага язды шөпшәләр.

Ап-ак көймәләрдә йөздек,
Ишкәк иштек куышып,
Велосипедларда йөрдек,
Юллар буйлап узышып...

Һәй-й, аларны сөйләп чыгу
Мөмкинмени тиз генә?
Җәйнең шундый кызыклыгын
Белми кемегез генә?..

Шулай булды: бик шәп итеп
Ял иттек без рәхәттә.
Көчләр җуеп, буйга үсеп,
Инде килдек мәктәпкә.

Сагнып кайттык без мәктәпне,
Укыткан апаларны,
Үзебезнең дус отрядны,
Сөекле китапларны.

Инде хәзер, көч кызганмый,
Укырбыз көне-төне.
Сизмәбез дә кыш узганны,
Тагын җитәр җәй көне!



Эчтәлек

Яхшы бел 2
Кояш, чык, чык! 2
Күгәрченнәр гөрли 3
Булмасын 4
Күзлек кайда? 5
Бәбкәләр 7
Апам белән 8
Хуш килдегез! 8
Әлифба 9
Киңәш 11
Әйтеп кара 11
Яратам 12
Алай итмә 12
Тырыш кыз 13
Җәй җыры 14
Су буе 15
Яшь туристлар җыры 16
Күңел һаман сиңа тарта 17
Печән җыйганда 19
Ике тәкә 20
Җәйге кичтә 21
Кәҗә, кәбестә, бүре 22
Сагынып кайттык 23

Издание для детей и юношества

Шайхи Маннур

ЗДРАВСТВУЙ, СОЛНЦЕ!
(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Л.З.Шиһапова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.12.2004. Форматы $60\times90\ ^1/_8$.
Офсет кәгазе. «Pragmatica» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 3,0. Шартлы буяу-оттиск 20,0. Нәшер-хисап табагы 3,54.
Тиражы 5000 д. Заказ Э-921

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.